Зеленодольск муниципаль
районы Советының «2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы
муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән расланган
Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге
Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»
карары проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында
ЙОМГАКЛАУ

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 2015 елның 08 мартындагы 23-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе административ суд эшчәнлеге кодексын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында», 2015 елның 30 мартындагы 63-ФЗ номерлы «Муниципаль хезмәт өчен кадрлар әзерләү механизмын камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында», 2015 елның 03 ноябрендәге 303-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законнар, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында», 2015 елның 21 июлендәге 59-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 15, 99-101 статьялары белән, Зеленодольск муниципаль районы Советының 2015 елның 15 декабрендәге 36 номерлы “2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән расланган Татарстан Республикасы “Зеленодольск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Зеленодольск муниципаль районы Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү һәм карар проекты турында" карары нигезендә ачык тыңлаулар үткәрелде.

Үткәрү датасы: 2015 елның 28 декабре

Үткәрү вакыты: 16.00 сәгать

Үткәрү урыны: Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 46 йорт, А.М. Горький исемендәге мәдәният һәм халык иҗаты үзәге

Зеленодольск муниципаль районы Советының «2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты халыкны таныштыру өчен Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырылган.

Зеленодольск муниципаль районы Советының «2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»

карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру өчен кирәкле барлык процедуралар тиешенчә үтәлгән.

Сөйләшә торган мәсьәлә буенча гражданнардан тәкъдимнәр, ачык тыңлауларда катнашуга гаризалар Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына килмәде.

Зеленодольск муниципаль районы Советының «2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча ачык тыңлауларда катнашучылар карар проектын хупладылар һәм аны раслауга тәкъдим иттеләр.

Зеленодольск муниципаль районының
Башкарма комитет
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин